РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

4 февраль, 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәрендә гражданнар арасында сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясындагы 4 пункты нигезендә, Кукмара шәһәрендә яшәүчеләрнең җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу хокукларын тәэмин итү, шәһәрдә халык арасында сораштыру оештыру һәм уздыру өчен хокукый һәм оештыру нигезен булдыру максатыннан, Кукмара шәһәр Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәрендә гражданнар арасында сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне кушымтага нигезләнеп расларга
2. «Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәр тибындагы бистәсендә гражданнар арасында сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» 2006 елның 7 декабрендәге 33 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының 2022 елның 4 февралендәге 4 номерлы карарына кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КУКМАРА ШӘҺӘРЕНДӘ ГРАЖДАННАР АРАСЫНДА СОРАШТЫРУНЫ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ УЗДЫРУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1 бүлек Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья Гражданнар арасында сораштыру уздыру

Сораштыру уздыру халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуының бер формасы булып тора.

Сораштыру Кукмара шәһәренең бөтен территориясендә (текстта алга таба – Җирлек) яисә аның территориясенең бер өлешендә Җирлек халкының фикерен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә исәпкә алу өчен үткәрелә.

### 2 статья. Җирлектә гражданнар арасында сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне җайга салу предметы

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Конституцияләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав) нигезендә Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәрендә гражданнар арасында сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) шәһәр гражданнары арасында сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибен билгели.

### 3 статья. Гражданнарның сораштыруда катнашу хокукы

Гражданнар арасында сораштыруда сайлау хокукына ия Җирлек халкы катнашырга хокуклы.

### 4 статья. Сораштыруның принциплары

1. Җирлек халкы сораштыруда турыдан-туры катнаша. Сораштыруда катнашучы һәр кеше бер генә тавышка ия.
2. Сораштыруда катнашу ирекле һәм ихтыяри. Сораштыру вакытында беркем дә үз фикерләрен һәм инануларын белдерергә яки алардан баш тартырга мәҗбүр ителә алмый.
3. Сораштыруны әзерләү, уздыру һәм нәтиҗәләрен билгеләү ачык һәм хәбәрдар рәвештә гамәлгә ашырыла.
4. Сораштыру нәтиҗәләре җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары өчен тәкъдим итү характерында.

### 5 статья. Сораштыруга чыгарылган мәсьәләләр

1. Сораштыруга түбәндәге мәсьәләләр чыгарылырга мөмкин:
- Устав белән билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр;
- муниципаль берәмлек җирләренең төбәк һәм төбәкара әһәмияттәге объектларга максатчан билгеләнешен үзгәртү мәсьәләләре.

2. Сораштыруга чыгарыла торган мәсьәләләр төгәл формалаштырылган булырга тиеш, аларны төрлечә аңлату мөмкинлеге булу рөхсәт ителми.

6 статья. Сораштыру уздыру ысуллары

1. Сораштырулар бер яки берничә көн дәвамында яшерен, исемле яки ачык тавыш бирү юлы белән үткәрелә.
2. Яшерен тавыш бирү сораштыру уздыру участокларында сораштыру кәгазьләре буенча үткәрелә.
3. Исемле тавыш бирү сораштыру кәгазьләре яисә сораштыру исемлекләре буенча сораштыру уздыру участокларында һәм (яки) сораштыруда катнашучыларның яшәү урыны буенча үткәрелә.
4. Сораштыру шулай ук гражданнар җыелышларында ачык тавыш бирү формасында үткәрелергә мөмкин.

## 2 бүлек Сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе

7 статья. Сораштыру уздыру инициаторлары

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча сораштыру Кукмара шәһәре Советы яисә Җирлек Башлыгы инициативасы белән үткәрелә.
2. Төбәк һәм төбәкара әһәмияттәге объектлар өчен муниципаль берәмлек җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү мәсьәләләре буенча сораштыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча уздырыла.

8 статья. Сораштыруны билгеләү турында карар кабул итү

1. Гражданнар арасында сораштыруны билгеләү турында карар Кукмара шәһәре Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру уздыру өчен, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Гражданнар арасында сораштыруны билгеләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:
1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;
2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган мәсьәләне (мәсьәләләрне) формалаштыру;
3) сораштыру уздыру методикасы;
4) сораштыру кәгазе формасы;
5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;
6) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.
2. Сораштыру, сораштыру уздыру турында карар кабул ителгәннән алып, кимендә бер айдан соң һәм алты айдан да соңга калмыйча үткәрелә.
3. Массакүләм мәгълүмат чараларында сораштыру уздыру турындагы рәсми мәгълүмат аны уздыруга кадәр кимендә ун көн алдан бастырылырга тиеш.

9 статья. Сораштыру уздыру буенча комиссия

1. Җирлектә сораштыру үткәргән вакытта комиссиянең сораштыру уздыру буенча функцияләре Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясенә ( алга таба – Сайлау комиссиясе) йөкләнә.
2. Сайлау комиссиясе:
- сораштыру уздырган вакытта, әлеге Нигезләмәнең үтәлешен оештыра;
- массакүләм мәгълүмат чаралары аша сораштыруга чыгарылган мәсьәлә, сораштырулар уздыру вакыты һәм тәртибе турында халыкка хәбәр итүне оештыра;
- сораштыру кәгазьләрен (сораштыру исемлекләрен) әзерләүне тәэмин итә;
- шәһәрдә сораштыру нәтиҗәләрен билгели;
- җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән хезмәттәшлек итә;

- округ һәм участок комиссияләре эшчәнлеген координацияли;
- әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Сораштыру уздырган вакытта тавыш бирү процессын тәэмин итү өчен, Сайлау комиссиясе сораштыру уздыру буенча округ һәм участок комиссияләре составын раслый.

4. Округ комиссиясе:

- әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип буенча тиешле территорияләрдә сораштыру әзерләүне һәм уздыруны оештыра;
- участок комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата гражданнарның гаризаларын һәм шикаятьләрен карый;
- халыкка сораштыруга чыгарыла торган мәсьәлә, сораштырулар уздыру вакыты һәм тәртибе турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә;
- тиешле территориядә сораштыру нәтиҗәләрен билгели, сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә төзи, аны Сайлау комиссиясенә тапшыруны тәэмин итә;
- тиешле территориядә үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастыра;
- участок комиссияләре эшен контрольдә тота;
- әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5. Участок комиссиясе:

- халыкка участок комиссиясенең адресы һәм телефон номеры, сораштыру уздыру периоды (датасы), вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;
- сайлау хокукына ия булган кешеләр исемлеген аныклый, әлеге исемлектә хаталар һәм төгәлсезлекләр турында гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләләрне хәл итә;
- тавыш бирү өчен биналар, тартмалар һәм башка җайланмалар әзерләүне тәэмин итә;
- әлеге Нигезләмәнең 10 статьясы, 3 өлеше нигезендә сораштыру уздыру буенча тиешле участокта сораштыруның бөтен периоды дәвамында агитация алып баруны тыюның үтәлешен тикшереп тора;
- әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртипкә туры китереп, сораштыруда катнашучыларның тавыш бирүләрен уздыруны оештыра;

сораштыру уздыру буенча тиешле участокта сораштыру нәтиҗәләрен билгели, сораштыру йомгаклары турында беркетмә төзи, аны округ комиссиясенә тапшыруны тәэмин итә;

- үз вәкаләтләре чикләрендә сораштыру уздырган вакыттагы хокук бозуларга карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;
- әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6. Әгәр Сайлау комиссиясенә әлеге комиссияләрнең тавыш бирү һәм (яки) тавышларны санау тәртибе бозылуга китергән гамәлләренә карата шикаятьләр (гаризалар) кермәсә, округ һәм участок комиссияләренең вәкаләтләр чоры сораштыру нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән ун көннән соң тәмамлана.

Сораштыру уздырган вакытта тавыш бирү нәтиҗәләренә карата шикаять белдерелгән очракта, тиешле округ яки участок комиссияләренең вәкаләтләре Сайлау комиссиясе карары буенча туктатыла.

10 статья. Сораштыруны әзерләү һәм уздыру вакытында хәбәрдарлык

1. Сораштыруны әзерләү, уздыру һәм нәтиҗәләрен билгеләү ачык һәм хәбәрдар рәвештә гамәлгә ашырыла.

Сораштыру уздыру участокларында сораштыру уздырганда һәм йомгак ясаганда, югарыдагы комиссия әгъзалары, шәһәр территориясендә теркәлгән иҗтимагый берләшмәләрдән, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарыннан күзәтүчеләр, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.

2. Кызыксынган якларга сораштыруга чыгарыла торган мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча үз карашларын бәян итүгә тигез хокуклар бирелергә тиеш.

3. Сораштыру башланасы көннән алдагы көндә һәм бөтен сораштыру периодында агитация үткәрү тыела.

11 статья. Күзәтүчеләр

Җирлек территориясендә теркәлгән иҗтимагый берләшмәләр, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары тарафыннан һәр участок комиссиясенә сораштырулар уздыру буенча участокларда чиратлап күзәтү үткәрергә хокуклы күп дигәндә биш күзәтүче билгеләнергә мөмкин. Шул ук вакытта бер иҗтимагый берләшмә яки территориаль иҗтимагый үзидарә мәнфәгатьләрен кайгыртучы күзәтүче вәкаләтләрен ике яисә берничә күзәтүче тарафыннан бер үк вакытта гамәлгә ашыру рөхсәт ителми.

Күзәтүченең вәкаләтләре мәнфәгатьләрен әлеге күзәтүче тәкъдим иткән иҗтимагый берләшмә, территориаль иҗтимагый үзидарә тарафыннан бирелгән юлламада таныкланырга тиеш.

Юлламада күзәтүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны адресы, әлеге күзәтүче җибәрелә торган сораштыру уздыру пункты адресы күрсәтелә. Юллама паспорт яки аны алмаштыручы документ күрсәткәндә гамәлдә була.

12 статья. Сораштыру уздыру буенча участоклар

1. Сайлау комиссиясе сораштыру уздыру буенча участокларның схемасын һәм аның график сурәтен билгели һәм Кукмара шәһәре Советына карауга һәм раслауга тапшыра.

Сораштырулар уздыру буенча комиссияләрнең һәм участокларның урнашу урыннары, аларның чикләрен һәм номерларын күрсәтеп, сораштыруга кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бастырылырга тиеш.

2. Сораштырулар уздыру участоклары җирле һәм башка шартларны исәпкә алып, сораштыруда катнашучылар өчен максималь уңайлыклар тудыру зарурлыгыннан чыгып, шулай ук сораштыру уздыру буенча бер участокта сораштыруда катнашучы өч меңнән артык кеше теркәлергә тиеш түгеллеген исәпкә алып оештырыла.

3. Сораштыру уздырган вакытта тавыш бирү өчен биналар участок комиссиясе карамагына түләүсез бирелә.

13 статья. Сораштыруда катнашу хокукына ия гражданнар исемлеге

1. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә актив сайлау хокукына ия булган кешеләр кертелә. Исемлектә сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы (18 яшьтә – өстәмә рәвештә көне һәм ае) һәм яшәү урыны күрсәтелә.

Сораштыру уздыру буенча конкрет участокта сораштыруда катнашучылар исемлегенә җирлектә яшәүчене кертү өчен нигез булып, аның яшәү урынының әлеге участок территориясендә булу факты тора.

Җирлектә яшәүче сораштыруда катнашучылар исемлегенә бары тик сораштыру уздыру буенча бер участокта гына кертелә.

2. Сораштыруда катнашучылар исемлеге буларак сайлаучылар исемлеге кулланылырга мөмкин.

3. Сораштыруда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә, һәм комиссия рәисе һәм исемлекне төзегән секретарь тарафыннан имзалана.

Исемлекнең бер нөсхәсе участок комиссиясендә була. Сораштыруда катнашучылар исемлегенең икенче нөсхәсе электрон рәвештә саклана.

Сораштыруда катнашучылар исемлеге Сайлау комиссиясе һәм участок комиссияләре мөһерләре белән раслана.

4. Әлеге Нигезләмә нигезендә сораштыруда катнашу хокукына ия булган кешеләрне исемлеккә өстәмә кертү теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сораштыру уздырылган көнне дә рөхсәт ителә.

Тавышларны санау башланганнан соң, сораштыруда катнашу хокукына ия булган кешеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү тыела.

5. Сораштыруда катнашучылар исемлеге сораштыру уздырылганчы 10 көннән дә соңга калмыйча төзелә.

14 статья. Сораштыру кәгазе

1. Сораштыру кәгазендә сораштыруга чыгарылган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) төгәл бирелгән тексты була, һәм тавыш бирүченең «РИЗА» яки «КАРШЫ» сүзләре белән ихтыяр белдерү вариантлары күрсәтелә, алар астына буш шакмаклар урнаштырыла.

2. Сораштыруга берничә мәсьәлә чыгарылганда, алар бер сораштыру кәгазенә кертелә, эзлекле рәвештә номерлана һәм бер-берсеннән горизонталь линияләр белән аерыла. Норматив хокукый акт проектының сораштыруга чыгарылган нинди дә булса статьясының яисә нинди дә булса пунктының альтернатив редакцияләре шулай ук эзлекле рәвештә номерлана.

Исемле тавыш бирү өчен кулланыла торган сораштыру кәгазендә тавыш бирүче турында мәгълүмат кертү өчен буш урын булырга тиеш.

Сораштыру кәгазендә аны тутыру тәртибе турында аңлатма бирелә. Кәгазьнең уң өске почмагында участок комиссиясенең ике әгъзасы имзалары куела.

Сораштыруга берничә сорау чыгарылганда, алар сораштыру кәгазендә эзлекле рәвештә урнашалар.

15 статья. Сораштыру исемлеге

1. Сораштыру исемлеге графаларына сораштыруда катнашучыларның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, яшәү урыны, паспортының яисә аны алыштыра торган документның сериясе һәм номеры турында мәгълүмат кертелгән таблицадан гыйбарәт. Сораштыруга чыгарылган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) төгәл бирелгән тексты астында әлеге графалардан унда «РИЗА» яки «КАРШЫ» сүзләре белән тавыш бирүченең җавап вариантлары күрсәтелә, һәм тавыш бирүдә катнашучылар имзасы өчен урын калдырыла.

2. Сораштырулар исемлеге һәр биттә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

16 статья. Гражданнар җыелышларында тавыш бирү

1. Участок комиссиясе, әгәр сораштыруда катнашучылар саны бер меңнән артмаса, сораштыруга чыгарылган мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча тавыш бирү уздыру өчен, сораштыруда катнашучылар җыелышын үткәрергә хокуклы. Җыелышта катнашучыларны теркәү сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча үткәрелә. Җыелышны кимендә өч кешелек участок комиссиясе вәкилләре ачып җибәрә һәм алып бара. Җыелышта кызыксынган якларның сораштыруга чыгарылган мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча чыгышлары рөхсәт ителә, гражданнарның сорауларына җаваплар бирелә, әмма фикер алышу үткәрелми.

2. Җыелышта тавыш бирү һәр мәсьәлә буенча аерым «РИЗА» һәм аерым «КАРШЫ» дип үткәрелә. Тавыш бирүдә исемлеккә кертелгән һәм җыелышта теркәлгән сораштыруда катнашучылар гына катнаша.

Тавыш бирү нәтиҗәләре участок комиссиясенең җыелышта катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертелә.

3. Җыелыш сораштыруда катнашучылар исемлегенә кертелгән халыкның 25 проценттан артыгы катнашында тулы хокуклы.

17 статья. Сораштыруда яшерен тавыш бирү

1. Сораштыруда яшерен тавыш бирү сораштыру уздыру буенча участокларда үткәрелә. Сораштыру уздыру участокларында яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган урыннар урнаштырыла, һәм тавыш бирү өчен тавыш бирү вакытында печатьләп куела торган стационар

тартмалар куела. Тавыш бирүчегә сораштыру кәгазе участок комиссиясе әгъзалары тарафыннан сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча бирелә. Сораштыру кәгазен алганда, тавыш бирүче паспорт яки гражданин паспортын алмаштыручы башка документ күрсәтә һәм сораштыру исемлегендә үз фамилиясе каршына имза сала. Сораштыруда катнашучылар исемлегендә паспорт мәгълүматларын тутыру таләп ителми.

Тавыш бирүченең мөстәкыйль рәвештә сораштыру кәгазе алуы хакында имза салырга мөмкинлеге булмаса, ул, участок комиссиясе әгъзаларыннан, күзәтүчеләрдән тыш, башка зат ярдәменнән файдалана ала. Тавыш бирүчегә ярдәм күрсәткән зат, үз фамилиясен күрсәтеп, «Сораштыруда катнашучының сораштыру кәгазе алу турында имзасы» графасында сораштыруда катнашучылар исемлегендә имза сала.

2. Сораштыру кәгазе махсус җиһазландырылган урында (кабиналарда яки бүлмәләрдә) тавыш бирүче тарафыннан тутырыла, анда башка затлар булу рөхсәт ителми, һәм тавыш бирү тартмасына төшерелә. Мөстәкыйль рәвештә сораштыру кәгазен тутыра алмаган тавыш бирүче, участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче булмаган башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Әлеге затның фамилиясе сораштыруда катнашучылар исемлегендә сораштыру кәгазен алу турында тавыш бирүче имзасы белән янәшә күрсәтелә.

3. Тавыш биргәндә сораштыруда катнашучы «РИЗА» яки «КАРШЫ» сүзләре астындагы квадратта үзенең ихтыяры нигезендә теләсә нинди тамга куя. Участок комиссиясе әгъзалары тавыш бирүнең серлелеген тәэмин итәләр.

Әгәр тавыш бирүче сораштыру кәгазен тутырганда хата ясаган дип санаса, ул сораштыру кәгазен биргән участок комиссиясе әгъзасына бозылганы урынына яңа сораштыру кәгазен бирүне сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Участок комиссиясе әгъзасы тавыш бирүчегә яңа сораштыру кәгазе бирә, шул ук вакытта сораштыруда катнашучылар исемлегендә әлеге катнашучының фамилиясенә каршы тиешле тамга ясый. Бозылган сораштыру кәгазе гамәлдән чыгарыла (погашается), бу хакта акт төзелә.

Тутырылган сораштыру кәгазьләре тавыш бирүчеләр тарафыннан тавыш бирү тартмасына төшерелә, ул участок комиссиясе әгъзаларына күренә торган урында булырга тиеш. Тавыш бирү өчен тартмалар саны комиссия тарафыннан билгеләнә.

Тавыш бирү өчен күчермә тартмалар кулланып тавыш бирүне уздыру турындагы мәсьәләне участок комиссиясе мөстәкыйль хәл итә.

4. Әгәр участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче яки башка затлар тавыш бирү серен боза яки сораштыруда катнашучыларның ихтыяр белдерүенә йогынты ясарга омтыла икән, участок комиссиясе әгъзасы кичекмәстән аның эшендә катнашудан читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар бинадан чыгарып җибәрелә. Бу хакта дәлилләнгән карар участок комиссиясе тарафыннан язмача кабул ителә.

18 статья. Сораштыруда исемле тавыш бирү

1. Исемле тавыш биргәндә, паспорт яки гражданин паспортын алмаштыручы башка документ күрсәтеп тавыш бирүче сораштыру исемлегендә үз фамилиясенә каршы «плюс» тамгасын яки аның ихтыяр белдерүенә туры килә торган графадагы теләсә кайсы башка тамганы куя һәм имза сала.

2. Исемле тавыш бирү сораштыру кәгазьләре буенча сораштыру уздыру участокларында яисә сораштыруда катнашучыларның яшәү урыны буенча үткәрелергә мөмкин. Тавыш бирүче сораштыру кәгазенә үз фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, адресын яза, «РИЗА» яки «КАРШЫ» сүзләре астындагы квадратта үзенең ихтыяры нигезендә теләсә нинди тамга куя һәм имза сала. Тавыш бирүче үтенече буенча тавыш бирүче турында мәгълүматны сораштыру кәгазенә участок комиссиясе әгъзасы кертә ала, ләкин тиешле квадратта тавыш бирүче үзе тамга куя һәм имза сала.

3. Сораштыруда катнашучыларның яшәү урыны буенча исемле тавыш бирүләр үткәргәндә, участок комиссиясе әгъзалары сораштыру кәгазе кулланалар. Сораштыру кәгазе буенча тавыш бирү мәгълүматлары сораштыру нәтиҗәләренә ирешү өчен төп документ булып торган сораштыру исемлегенә кертелә.

3 бүлек Сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү

19 статья. Сораштыру нәтиҗәләре турында участок комиссиясе беркетмәсе

1. Сораштыру үткәргәннән соң, участок комиссиясе тавыш бирү нәтиҗәләрен исәпләп чыгара һәм сораштыру нәтиҗәләре турында үзенең карарын сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә белән рәсмиләштерә, анда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

нөсхәнең номеры;

«Беркетмә» сүзе;

сораштыру үткәрелгән мәсьәләнең формулировкасы;

сораштыру уздыру буенча участок адресы;

сораштыруда катнашу өчен исемлеккә кертелгән кешеләрнең гомуми саны;

сораштыруда катнашкан халык саны;

сораштырулар исемлегендәге гамәлгә яраксыз булган язмалар саны һәм гамәлгә яраксыз дип танылган сораштыру кәгазьләре саны;

сораштыруга чыгарылган мәсьәлә яклы бирелгән тавышлар саны;

сораштыруга чыгарылган мәсьәләгә каршы бирелгән тавышлар саны;

сораштыру нәтиҗәләре (әгәр аның өчен тавыш бирүдә катнашкан сораштыруда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, мәсьәлә хупланган дип санала);

участок комиссиясе рәисенең, рәисе урынбасарының, секретаренең, башка әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары һәм аларның имзалары;

беркетмәгә имза салу датасы һәм вакыты.

2. Әгәр сораштыру берничә мәсьәлә буенча үткәрелсә, тавышларны санау һәм беркетмә төзү һәр мәсьәлә буенча аерым башкарыла.

3. Сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес итеп билгеләргә мөмкин булмаган яки тавыш бирүче турында мәгълүмат яки аның имзасы булмаган, шулай ук кабатланучы язмалар булган сораштыру исемлегендәге язмалар гамәлгә яраксыз дип танылa.

Билгеләнмәгән үрнәктәге сораштыру кәгазьләре, участок комиссиясе әгъзалары тамгалары булмаган, шулай ук сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес итеп билгеләп булмый торган кәгазьләр, ә исемле тавыш бирү очрагында – тавыш бирүче турында мәгълүмат яки аның имзасы булмаган сораштыру кәгазьләре гамәлгә яраксыз дип танылa.

4. Беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән участок комиссиясе әгъзасы аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул беркетмәгә кушып бирелә.

5. Сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә 2 нөсхәдә төзелә һәм участок комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана. Сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук күрсәтелгән комиссиягә әлеге Нигезләмәне бозган өчен кергән язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Шикаятьләрнең, гаризаларның һәм алар буенча кабул ителгән карарларның расланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлә.

Имза салынганнан соң, сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмәнең ике нөсхәсе дә сораштыру исемлекләре һәм югарыда күрсәтелгән документлар белән бергә участок комиссиясе рәисе, сәркатибе яисә участок комиссиясе рәисе кушуы буенча башка әгъзасы тарафыннан округ комиссиясенә җибәрелә.

20 статья. Округ комиссияләрендә сораштыру уздыруга йомгак ясау

1. Округ комиссиясе, участок комиссияләренең сораштыру нәтиҗәләре беркетмәләре нигезендә, аларда булган мәгълүматларны кушу юлы белән, тиешле территориядә сораштыру нәтиҗәләрен билгели һәм аларны үзе төзи торган беркетмәгә кертә.

Округ комиссиясе беркетмәсенә әлеге Нигезләмәнең 19 статьясындагы 1 пункты нигезендә куела торган барлык таләпләргә өстәмә рәвештә участок комиссияләренең саны, участок комиссияләренең кергән беркетмәләре саны турында белешмәләр, шулай ук түбәндәге карарларның берсе кертелә:

- сораштыруны узган дип тану;
- сораштыруны узмаган дип тану;
- сораштыруны гамәлгә яраксыз дип тану;

2. Сораштыруда катнашкан кешеләр саны Кукмара шәһәр Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турындагы карарында билгеләнгән минималь саннан күбрәк булса, Округ комиссиясе сораштыруны узган дип таный.

2. Сораштыруда катнашкан кешеләр саны Кукмара шәһәре Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турындагы карарында билгеләнгән минималь саннан азрак булса, Округ комиссиясе сораштыруны узмаган дип таный.

4. Сораштыруны уздырганда җибәрелгән хокук бозулар тавыш бирү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, Округ комиссиясе сораштыру нәтиҗәләрен гамәлгә яраксыз дип саный.

5. Беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән округ комиссиясе әгъзасы аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул беркетмәнең беренче нөсхәсенә кушып бирелә. Сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсенә шулай ук округ комиссиясенә кергән участок комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Шикаятьләрнең, гаризаларның һәм алар буенча кабул ителгән карарларның расланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлә.

6. Беркетмәнең беренче нөсхәсе күчермәләре массакүләм мәгълүмат чаралары, җирле иҗтимагый берләшмәләр һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнары вәкилләренә танышу өчен тапшырылырга мөмкин.

7. Округ комиссиясе рәисе, секретаре яки башка әгъзасы Сайлау комиссиясенә сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә тапшыра.

21 статья. Уздырылган сораштыру нәтиҗәләренә Сайлау комиссиясе тарафыннан гомуми йомгак ясау

1. Округ комиссияләре беркетмәләре мәгълүматлары буенча, Сайлау комиссиясе аларда булган мәгълүматларны кушу юлы белән шәһәр буенча сораштыру нәтиҗәләрен билгели һәм, сораштыру тәмамланган соң 3 көннән дә соңга калмыйча, сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә төзи.

2. Сайлау комиссиясе беркетмәсенә әлеге Нигезләмәнең 19 статьясындагы 1 пункты нигезендә куела торган барлык таләпләргә өстәмә рәвештә округ комиссияләренең саны, округ комиссияләренең кергән беркетмәләре саны турында белешмәләр кертелә.

3. Беркетмәгә имза салу өчен, Сайлау комиссиясе йомгаклау утырышы үткәрә, анда тавыш бирүне уздыруга, тавышларны санауга һәм сораштыру уздыру буенча участок һәм округ комиссияләре тарафыннан беркетмәләр төзүгә бәйле кергән шикаятьләр (гаризалар) карала.

4. Сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм Сайлау комиссиясендә булган барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

5. Сораштыру нәтиҗәләре белән беркетмәнең беренче нөсхәсе Кукмара шәһәре Советына җибәрелә. Сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсенә Сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре кушып бирелә, шулай ук комиссиягә кергән түбәндәрәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә.

6. Сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе, комиссия әгъзаларының расланган аерым фикерләренең, түбәндәрәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрнең, гаризаларның расланган күчермәләре белән бергә, Сайлау комиссиясендә саклауда кала.

7. Сораштыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча үткәрелгән очракта, сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә Сайлау комиссиясе тарафыннан өч нөсхәдә төзелә, һәм беркетмәнең бер нөсхәсе сораштыру инициаторы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы адресына җибәрелә.

8. Кукмара шәһәре Советы яки Җирлек Башлыгы инициативасы белән үткәрелә торган сораштыру материаллары Кукмара шәһәре Советы депутатларының вәкаләтләре срогы дәвамында Кукмара шәһәре Советында саклана, ә аннары муниципаль архивка саклауга җибәрелә.

Күрсәтелгән материалларны саклау срогы Кукмара шәһәре Советы тарафыннан билгеләнә, әмма 1 елдан да ким була алмый.

22 статья. Сораштыру нәтиҗәләре

Сораштыру нәтиҗәләре Сайлау комиссиясе тарафыннан рәсми мәгълүматны бастыра торган массакүләм мәгълүмат чаралары аша, сораштыру тәмамланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча, халыкка җиткерелә.

Сораштыру нәтиҗәләре җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә исәпкә алына.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләренә каршы килә торган карарлар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән органнар, карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә массакүләм мәгълүмат чаралары аша мондый карар кабул ителүнең сәбәпләрен халыкка җиткерергә тиеш.

4 бүлек. Финанс белән тәэмин итү һәм сораштыру үткәргәндә җаваплылык

23 статья. Сораштыру уздыруны финанс ягыннан тәэмин итү

Гражданнар арасында сораштыру әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чараларны финанслау түбәндәгеләрнең акчалары хисабына гамәлгә ашырыла:

1) Җирлек бюджеты – җирле үзидарә органнары яисә муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә.

24 статья. Гражданнарның сораштыруда катнашу хокукларын бозган өчен җаваплылык

Көчләү, сатып алу, янау, ялган документлар ясау юлы яисә башка ысул белән Россия Федерациясе гражданының сораштыруда катнашу хокукын ирекле гамәлгә ашыруына комачаулаучы затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.